**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ядегәр авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 30 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок- Шәмәрдән авылы, М.Җәлил урамы, 6 нчы а йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр урта мәктәбе филиалы бинасында үткәрергә.
2. 2020 елның 1 декабренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок- Шәмәрдән авылы, М.Җәлил урамы, 6 нчы а йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр урта мәктәбе филиалы бинасында үткәрергә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Починок- Шәмәрдән авылында кышын юлларны карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Починок- Шәмәрдән авылының Совет урамнары буенча юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Починок-Шәмәрдән авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы А.Н.Фәйзуллин